**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» сентябрь, 2021 ел № 637

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 06 февралендәге 217 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының «Халыкара автомобиль ташуны гамәлгә ашыруны дәүләт контроле турында һәм аларны үтәү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында» Федераль законның 2 һәм 6 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 02 июлендәге 337-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 2 һәм 6 статьяларына туры китерү максатларында Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими

рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 06 февралендәге 217 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 9.5 пунктта «пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны» сүзләреннән соң «(даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның халыкара маршруты картасыннан тыш)» сүзләрен өстәргә;

- 9.4 пунктының беренче абзацында «пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны» сүзләреннән соң «(даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның халыкара маршруты картасыннан тыш)» сүзләрен өстәргә;

- 4.6 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль, муниципальара, катнаш регионара маршрутлары реестрларына түбәндәге белешмәләр кертелергә тиеш:».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.Р. Байгильдинга йөкләргә.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — Э.А. Штейн